**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **с. Тюлячи** **КАРАР**

«24» июля 2023г. № 112

Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләргә муниципаль социаль заказ формалаштырганда социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында

«Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләргә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба - Федераль закон) 28 статьясындагы 3 өлеше, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары (җирле үзидарә органнары) тарафыннан социаль өлкәдә дәүләт хезмәтләре күрсәтүне оештыру турында карарлар кабул итүгә гомуми таләпләрне раслау турында» 2020 елның 13 октябрендәге 1678 номерлы карары нигезендә, МКУ «Район Башкарма комитеты мәгариф бүлеге»нең 2023 елның 30 июнендәге 217 номерлы хатын карап, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш)» эшчәнлеге юнәлеше буенча Федераль закон нигезләмәләре нигезендә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештырырга һәм «Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказ турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган хезмәт күрсәтүләрне башкаручыларны сайлап алу ысулын апробацияләү гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәтләр исемлеген расларга, 1 номерлы кушымта нигезендә.

2. МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф бүлеге»н «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләргә муниципаль социаль заказны раслаучы вәкаләтле орган (алга таба - муниципаль хезмәтләр) дип билгеләргә.

3. «Мәгариф» милли проектының «һәр баланың уңышы» федераль

проекты чараларын гамәлгә ашыру кысаларында муниципаль берәмлек территориясендә Федераль законның 9 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган муниципаль хезмәтләр башкаручыларны сайлап алуның конкурентлык ысулын кулланып, балаларга өстәмә белем бирүне персональләштерелгән финанслау системасын кертү өлешендә «Өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш)»эшчәнлеге юнәлеше буенча Федераль закон нигезендә социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль социаль заказны формалаштыруны һәм үтәүне тәэмин итәргә.

4. Федераль законның 8 статьясында һәм 28 статьясының 3 өлешендә каралган таләпләрне үтәү максатларында, Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районында «Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүләргә дәүләт (муниципаль) социаль заказ турында» Федераль закон нормалары кулланыла дип билгеләргә.

5. МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге»нә социаль сертификат нигезендә «Өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру» муниципаль хезмәт күрсәтүгә муниципаль социаль заказ булдыруны һәм раслауны тәэмин итәргә.

6. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләр оештыру буенча эшче төркем турында Нигезләмәне 2 номерлы кушымта нигезендә расларга.

7. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләр оештыру буенча эшче төркем составын 3 номерлы кушымта нигезендә расларга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«24» 07 2023 елның
№ 112 карарына
1 номерлы кушымта

**«Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказ турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктында каралган хезмәт күрсәтүләрне башкаручыларны сайлап алу ысулын апробацияләү гамәлгә ашырыла торган муниципаль хезмәтләр исемлеге**

1. Өстәмә гомуми үстерү программаларын гамәлгә ашыру:

- 804200О.99.0.ББ52АЕ04000 (техник юнәлешле, укыту формасы: көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЕ16000 (техник юнәлешле, укыту формасы: гамәлгә куюның челтәр формасын кулланып көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЕ28000 (табигый-фәнни юнәлешле, укыту формасы: көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЕ40000 (табигый-фәнни юнәлешле, укыту формасы: гамәлгә куюның челтәр формасын кулланып көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЕ52000 (физкультура - спорт юнәлешле, укыту формасы: көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЕ64000 (физкультура - спорт юнәлешле, укыту формасы: гамәлгә куюның челтәр формасын кулланып көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЕ76000 (сәнгать юнәлеше, укыту формасы: гамәлгә куюның челтәр формасын кулланып көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЕ88000 (сәнгать юнәлешле, укыту формасы: гамәлгә куюның челтәр формасын кулланып көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЖ00000 (туристлык туган якны өйрәнү юнәлешле, укыту формасы: көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЖ12000 (туристлык туган якны өйрәнү юнәлешле, укыту формасы: гамәлгә куюның челтәр формасын кулланып көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЖ24000 (социаль - педагогик юнәлешле, укыту формасы: көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АЖ36000 (социаль-педагогик юнәлешле, укыту формасы: гамәлгә куюның челтәр формасын кулланып көндезге).

2. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән балалар өчен өстәмә гомумүстерү программаларын гамәлгә ашыру:

- 804200О.99.0.ББ52АН48000 (сәнгать юнәлешле, укыту формасы: көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АН96000 (социаль-педагогик (социаль-гуманитар) юнәлешле, укыту формасы: көндезге);
- 804200О.99.0.ББ52АН24000 (физкультура-спорт юнәлешле, укыту формасы: көндезге).

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«24» 07 2023 елның
№ 112 карарына
2 номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләр оештыру буенча эшче төркем турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләр оештыру буенча эшче төркем (алга таба - эшче төркем) коллегиаль киңәшмә органы булып тора.

1.2. Эшче төркем Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә «Социаль өлкәдә дәүләт (муниципаль) хезмәт күрсәтүгә дәүләт (муниципаль) социаль заказы турында» 2020 елның 13 июлендәге 189-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 2.1 өлешенең 3 пунктчасында билгеләнгән эшчәнлек юнәлешләренә (алга таба - 189-ФЗ номерлы Федераль закон) Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының муниципаль хезмәт күрсәтүләр буенча муниципаль социаль заказын формалаштыру буенча тәкъдимнәр әзерләгәндә Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы җирле үзидарә органнарының (алга таба - ҖҮО) үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү максатларында оештырылган.

1.3. Эшче төркем үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнары, Татарстан Республикасы законнары, башка норматив хокукый актлар һәм Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыру (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш)» муниципаль белем бирү оешмалары эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру буенча эшче төркем турында әлеге Нигезләмәгә таянып эш итә (алга таба - Нигезләмә).

1.4. Эшче төркемнең утырышлар йомгаклары буенча кабул ителгән карарлары тәкъдим характерында.

## 2. Эшче төркемнең бурычлары

Эшче төркемнең бурычлары түбәндәгеләр:

2.1. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә 189-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясындагы 2 өлешенең 3 бүлеге белән билгеләнгән эшчәнлекнең тиешле юнәлешләре буенча муниципаль социаль заказны формалаштыру һәм раслау буенча тәкъдимнәр әзерләү.

2.2. Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыруның 189-ФЗ номерлы Федераль

законында каралган механизмнарын апробациялəү өчен кирəкле чараларны гамəлгə ашыру буенча тəкъдимнəр əзерлəү.

2.3. Татарстан Республикасы Телəче муниципаль районы территориясендə муниципаль социаль заказны формалаштырганда һəм үтəгəндə мəгълүмати системалардан файдалану буенча тəкъдимнəр əзерлəү.

2.4. Әлеге Нигезлəмəнең 1.2 пунктында күрсəтелгəн эшче төркемне төзү максатына ирешүгə юнəлдерелгəн башка бурычларны гамəлгə ашыру.

## 3. Эшче төркем вəкалəтлəре

Әлеге Нигезлəмəнең 2 бүлегендə күрсəтелгəн бурычларны хəл итү өчен, эшче төркем түбəндəге вəкалəтлəргə ия:

3.1. Эшче төркем утырышларында эшче төркеме компетенциясенə кагылышлы мəсьəлəлəрне карарга.

3.2. Җирле үзидарə органнарыннан һəм муниципаль оешмалардан эшче төркем компетенциясенə кагылышлы мəсьəлəлəр буенча мəгълүмат соратып алырга.

3.3. Җирле үзидарə органнары һəм муниципаль оешмалар тарафыннан тапшырыла торган мəгълүматны, документларны һəм материалларны эшче төркем бурычлары нигезендə карарга.

## 4. Эшче төркем функциялəре

Эшче төркемнең төп функциялəре түбəндəгелəр:

4.1. Социаль өлкəдə муниципаль хезмəтлəр күрсəтүне оештыру буенча эшче төркем əгъзаларының тəкъдимнəрен Федераль закон нигезендə карау һəм 189-ФЗ номерлы Федераль законда каралган социаль өлкəдə муниципаль хезмəтлəр күрсəтүне оештыру механизмнарына апробация үткəрү.

4.2. Апробация планын гамəлгə ашыру өчен кирəкле оештыру, методик, технологик чараларны формалаштыру, билгелəү.

4.3. Апробация планын гамəлгə ашыруның барышын агымдагы мониторинг һəм тикшереп тору.

## 5. Эшче төркем эшчəнлеген оештыру

5.1. Эшче төркеме составы Татарстан Республикасы Телəче муниципаль районы Башкарма комитеты карары белəн раслана.

5.2. Эшче төркемне эшче төркем җитəкчесе җитəкли. Эшче төркем җитəкчесенең урынбасары бар. Эшче төркем җитəкчесе булмаганда, аны җитəкче урынбасары башкара.

5.3. Эшче төркеме җитəкчесе түбəндəге функциялəрне башкара:

- эшче төркем эшчəнлеген оештыра;
- эше төркем эшчəнлеген планлаштыра;
- эшче төркемнең чираттагы утырышында фикер алышу өчен көн тəртибен раслый;
- эшче төркеме утырышларын алып бара.

5.4. Эшче төркеме утырышлары кирəк саен уздырыла.

5.5. Эшче төркем утырышы, əгəр анда эшче төркем əгъзаларының кимендə яртысы катнашса, хокуклы дип санала.

5.6. Эшче төркем эшчәнлеген документлар белән тәэмин итү эшче төркем секретаре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.7. Эшче төркем секретаре:

- эшче төркем утырышларын әзерләүне һәм оештыруны гамәлгә ашыра;

- эшче төркем карарлары проектларын әзерләүне гамәлгә ашыра;

- эшче төркемнең утырышлар беркетмәләрен алып бара һәм проект комитетының беркетмә карарларының үтәлешен тикшереп тора;

- эшче төркем утырышлары нәтиҗәләре буенча мәгълүмат материалларын, документларны гомумиләштерә һәм әзерли.

5.8. Эшче төркем карары кабул ителгән дип санала, әгәр дә аның өчен эшче төркем әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше тавыш бирсә. Тавышлар тигез булганда, эшче төркем җитәкчесе яисә эшче төркем җитәкчесе урынбасарының, эшче төркем җитәкчесе вазыйфаларын башкаручының тавышы хәлиткеч булып тора.

5.9. Эшче төркем карары эшче төркем утырышы беркетмәсе (алга таба - беркетмә) белән рәсмиләштерелә, аңа эшче төркем җитәкчесе яисә эшче төркем рәисе вазыйфаларын башкаручы эшче төркем җитәкчесе урынбасары имза сала.

Беркетмәләрнең күчермәләре эшче төркемнең барлык әгъзаларына җибәрелә.

Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«24» 04 2023 елның
№ 112 карарына
3 номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы территориясендә «өстәмә белем бирү программаларын (сәнгать өлкәсендә өстәмә һөнәри программалардан тыш) гамәлгә ашыру» эшчәнлеге юнәлеше буенча социаль өлкәдә муниципаль хезмәт күрсәтүләр оештыру буенча эшче төркем составы**

| Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Вазыйфа |
|---|---|
| Эшче төркем җитәкчесе: | |
| Карпова Наталья Владимировна | МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» башлыгы. |
| Эшче төркем җитәкчесе урынбасары: | |
| Вахитова Миләүшә Госман кызы | МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» башлыгы урынбасары. |
| Эшче төркем секретаре: | |
| Әхмәтвәлиева Гөлназ Фәнис кызы | МКУ «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» методисты. |
| Эшче төркем әгъзалары: | |
| Мәхмүтова Зөлфия Шамил кызы | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы МБӨБУ «Балалар иҗат үзәге» директоры; |
| Шәйхетдинов Азат Рамазан улы | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы МБӨБУ БСББҮ директоры; |
| Сафина Резеда Камил кызы | Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы МБӨБУ «Балалар сәнгать мәктәбе» директоры. |